РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«12» март 2020г. г. Альметьевск №190

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы «Коррупциягә каршы тору турында»гы Федераль законга, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы ТР Законына үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә, ТР Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставының XV бүлеге нигезендә, 2019 елның 8 ноябрендәге халык тыңлаулары нәтиҗәләрен исәпкә алып,

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2011 елның 22 сентябрендәге 37 санлы карары белән расланган ТР Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына (Әлмәт шәһәр Советының 2012 елның 21 июнендәге 69 санлы, 2013 елның 4 июлендәге 104 санлы, 2014 елның 2 октябрендәге 139 санлы, 2015 елның 13 мартындагы 167 санлы, 2016 елның 29 апрелендәге 29 санлы, 2016 елның 28 декабрендәге 57 санлы, 2017 елның 27 июлендәге 86 санлы, 2018 елның 11 маендагы 116 санлы, 2019 елның 25 мартындагы 144 санлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләрне Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә юлларга.

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләрне, теркәгәннән соң, «Альметьевский вестник» һәм «Әлмәт таңнары» газеталарында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 44 нче маддәсе 8 нче өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне шәһәр башлыгы урынбасары А.М. Токаревка йөкләргә.

Шәһәр башлыгы «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ» Т.Д. Нагуманов

Зак. № 3774

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәр Советының
2020 елның 12 мартындагы
190 санлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының
Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр

1. 6 нчы маддәдә:

1.1. 6 нчы маддәнең 1 нче елеше 21 нче пунктын «территорияне планлаштыру буенча, бирү» дигән сүзләрдән соң «җирлек чикләрендә урнашкан җир участогының шәһәр төзелеше планы, бирү» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

1.2. түбәндәге эчтәлектәге 4 нче өлеш белән тулыландырырга:

«4. Шәһәрнең җирле үзидарә органнары, әлеге Уставның 6 нчы маддәсе 1 нче елешенең 8-10, 17 һәм 20 нче пунктларында күздә тотылган мәсьәләләрне хәл итү максатларында гражданнарны шәһәр өчен социаль әһәмиятле эшләрне (шул исәптән кизү торуларны) ирек- ле нигездә башкаруга җәлеп итү турында карар кабул итәргә хокуклы.

Соңиаль әһәмиятле эшләргә махсус һөнәри әзерлек таләп итми торган эшләр генә кертелергә мөмкин.

Социаль әһәмиятле эшләрне башкаруга шәһәрнең төп эштән яки укудан буш вакытында бушлай нигездә өч айга бер тапкырдан да артык булмаган рәвештә эшкә яраклы балигъ булган кешеләре җәлеп ителә ала. Бу вакытта социаль әһәмияткә ия эшләрнең дәвамлылыгы рәттән дүрт сәгатьтән артык тәшкил итә алмый.»;

2. 6 нчы маддәдә:

2.1. 2 нче өлешне түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«Даими нигездә шәһәр Советы депутатларының билгеләнгән санынннан 10 (ун) процентан да артык булмаган елеше эшли ала, калганнары, кагыйдә буларак, даими булмаган нигездә эшли.

Үз вәкаләтләрен даими нигездә тормышка ашыручы депутат, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарә сайланулы вазифаи затының түбәндәгеләргә хокукы юк:

1) шәхсән яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шегыльләнү;

2) коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан кала:

а) бушлай нигездә сәяси партия, профессиональ союз, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында булдырылган башлангыч профсоюз оешмасы сайланулы органы белән идарә итүдә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, торак милекчеләре ширкәте съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашу;

б) ТР Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Президентына (ТР дәүләт власте югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан белдерү кәгазе белән бушлай нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу (сәяси партия, профессиональ союз органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында тезелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә, башка иҗтимагый оешма, торак,

торак-төзелеш, гараж кооперативлары, торак милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашудан кала);

в) бушлай нигездә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен тәкъдим итү;

г) муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен яки муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен тормышка ашыру тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючысы (акционер, катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә итү һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен бушлай нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда күздә тотылган башка очраклар;

3) башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнү, мегаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән кала. Шул ук вакытта, әгәр Россия Федерациясе халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

4) әгәр РФ халыкара килешүендә яки РФ законнарында башкача каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр һәм күзәтчелек советлары, чит илләрнең коммерциячел булмаган, хөкүмәтнеке булмаган башка органнары һәм аларның РФ территориясендә эшләүче структур бүлекчәләре составына керү»;

2.2. 6 нчы өлештә «, муниципаль вазифаны биләүче башка зат,» дигән сүзләрне алып ташларга;

2.3. 8 нче елештә «җирле үзидарә сайланулы вазифаи заты» дигән сүзләрдән соң «яки әлеге затларга карата башка җаваплылык чаралары куллану» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

2.4. түбәндәге эчтәлектәге 8.1 елеше белән тулыландырырга:

«8.1. Үз керемнәре, чыгымнары, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милекләре һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында дерес һәм тулы булмаган белешмәләр биргән депутатка, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарә сайланулы вазифаи затына, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим түгел икән, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасын шәһәр Советында, җирле үзидарә сайланулы органында вазифасыннан азат итү белән бергә аның вәкаләтләре срогы беткәнче шәһәр Советында, җирле үзидарә сайланулы органында вазифа биләүдән мәхрүм итү;

3) вәкаләтләре срогы беткәнче аларны даими нигездә башкару хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрне башкарудан азат итү;

4) вәкаләтләре срогы беткәнче шәһәр Советында, җирле үзидарә сайланулы органында вазифа биләүне тыю;

5) вәкаләтләре срогы беткәнче даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.»;

2.5. түбәндәге эчтәлектәге 8.2 өлеше белән тулыландырырга:

«8.2. Депутатка, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарә сайланулы вазифаи затына әлеге маддәнең 8.1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.»;

3. 29 нчы маддәнең 1 нче өлеше 24 нче пунктын үз көчен югалткан дип санарга;

4. 36 нчы маддәнең 7 нче елешен түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«7. Шәһәр Советы депутаты, җирле үзидарә сайланулы вазифаи заты, муниципаль вазифаны биләп торучы башка затның вәкаләтләре 06.10.2003 елгы 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла.

Депутат, җирле үзидарә сайланулы вазифаи заты, муниципаль вазифаны биләүче башка затның вәкаләтләре, 06.10.2003 елгы 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон белән башкача күздә тотылмаганда, 25.12.2008 елгы 273-ФЗ санлы «Коррупциягә каршы тору турында»гы Федераль закон, 03.12.2012 елгы 230-ФЗ санлы «Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүенә контроль турында»гы Федераль закон, 07.05.2013 елгы 79-ФЗ санлы «Затларның аерым категорияләренә счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акча һәм кыйммәтле кәгазьләрне саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәгән, вазифаларны башкармаган очракта срогыннан алда туктатыла,»;

5. 43 нче маддәнең 3 нче өлешендә икенче җөмләне алып ташларга;

6. 45 нче маддәдә:

6.1. 1 нче өлешнең өченче абзацын түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«- шәһәр чикләрендә урнашкан җир участогының шәһәр төзелеше планын бирә, төзелешкә рөхсәт бирә, шәһәр территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын тезегәндә, реконструкцияләгәндә объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирә;»;

6.2. 1 нче өлешнең 4 нче пунктындагы дүртенче абзацны түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«- билгеләнгән тәртиптә торак биналарны торак булмаган биналарга һәм торак булмаган биналарны торак биналарына күчерү турында карар кабул итә, күпфатирлы йортта бүлмәләрне үзгәртеп коруны һәм яңадан планлаштыруны килештерә, билгеләнгән тәртиптә муниципаль һәм шәхси торак фондының торак бүлмәләрен, күпфатирлы йортларны, Россия Федерациясе яки Татарстан Республикасы милкендә булган барлык торак биналары авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип табылган күпфатирлы йортлардан тыш, яшәү өчен яраксыз дип таный»;

7. 64.2 маддәсенең 1 нче өлеше 2 нче пунктын «, әгәр башкасы федераль законнар белән күздә тотылмаса» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

8. 85 нче маддәне түбәндәге эчтәлектәге 5 нче өлеш белән тулыландырырга:

«5. Шәһәр бюджетына башка муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә субсидияләр бирелергә мөмкин.»;

9. 86 нчы маддәдә:

9.1. 1 нче өлешнең беренче абзацында «РФ Бюджет законнары һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актлар» дигән сүзләрне «бюджет хокук менәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар, гаммәви норматив йөкләмәләрне һәм РФ бюджет системасы бюджетларыннан физик затларга башка түләүләр буенча йөкләмәләрне бирә торган хокукый актлар нигезләмәләре, шулай ук бюджеттан акчалар бирү турында муниципаль контрактлар, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәү» дип алыштырырга;

9.2. 2 нче өлештә «бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» дигән сүзләрне алып ташларга;

9.3. 86 нчы маддәнең 3 нче елешен түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«3. Эчке муниципаль финанс контроле шәһәр башкарма власть органы булып торучы муниципаль финанс контроле органының контроль эшчәнлеге булып тора».

Шәһәр башлыгы Т.Д. Нагуманов